Р. Г. ВӘЛИТОВА, С. Г. ВАГЫЙЗОВ

ӘЛИФБА

Р. Г. ВӘЛИТОВА
С. Г. ВАГЫЙЗОВ

*Татарстан Республикасы
Мәгариф министрлыгы
тарафыннан расланган*

Дүртьеллык башлангыч
татар мәктәбенең
1 нче сыйныфы
өчен дәреслек

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2005

УДК 373.167.1 : 81.512.145*01
ББК 81.2Тат я71
В97

Рәсемнәрен һәм макетын
И. Л. Язынин ясады

«Мәгариф» нәшриятыннан

Сезнең кулыгызда — ил күләмендә дәрәҗәле дипломнарга лаек булып, ничәмә-ничә буын укытучылар, ата-аналар һәм сабыйларның мәхәббәтен казанган Әлифбаның 35 нче басмасы.

Ярты гасыр дәвамында татар балаларына хәреф таныткан әлеге дәреслекнең авторлары инде арабыздан китсәләр дә, КИТАП яши, ул әле яңа буыннарга да хезмәт итәр дип ышанабыз.

Якын үткәнебез ядкаре булган мәшһүр Әлифбаның чираттагы басмасын мөгаллимнәр Рәмзия Гыйләҗетдин кызы Вәлитова, Сәләй Гататдин улы Вагыйзовның һәм рәссам Иван Лаврентьевич Язынинның якты истәлегенә багышлыйбыз.

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

ISBN 5-7761-1493-4

© «Мәгариф» нәшрияты, 2001













А а



Ааа Ааа

У у



Ууу Ууу

у-а   у-а



Л л

а
ал
у
ул

ал | ул
ул | а-ла

Ул а-ла.

ааа а-ла

ууу у-а



Н н

На-на-на!

ун | ул | ал

а-на | а-ла

у
ун
а
На!

Ул а-на.

А-на а-ла.

ул ал | а-на
ун а-ла | а-ла

Ул а-на ..... .

Ул а-на .... . ун.

С с

а	су	ал	ул
ас	су-ла	Ал-су	ун
у	у	а-ла	а-на
су	су	са-ла	са-на

Ул Ал-су.
Ал-су су а-ла.



Ссс!

ас

ал	ул	у	а
ас	ун	су	на

а-ла	а-на	са-ла
са-ла	са-на	су-ла

Ал-су а-ла.

А-на су са-ла.

ла | на | са | су

Шш

аш	ун	су
ал	ул	шу

а
аш
у
шу

а-ла	са-ла
а-ша	су-ла



Аш.

Ул Ал-су.
Ал-су аш са-ла.
— Аш а-ша.

ул | ун | су | шу

Ал-су шу-а. А-на аш са-ла.



Ал-су, са-на. Ал-су, су-ла.

ла | на | са | су | ша | шу

М м

Му-са	ал-ма	а-ла	са-на
шу-са	ал-са	а-ша	ма-на



Му-у!

Му-са, ал-ма а-ша.
Ал-су, ал-ма а-ша.
Му-са ал-ма а-ла.
Ал-су ал-ма а-ла.

ал	ул	су	ас	у-ма
аш	ун	шу	аш	шу-ма

а-ла	а-на	су-ла	са-на
а-ша	а-са	са-ла	ма-на

Муса шуа. Ау-ау!

Алсу шуа.

а | у | л | н | с | ш | м

Ә ә

Әс-ма Лә-лә

а-на	а-ла	ал-ма	у-а
ә-нә	Лә-лә	Әс-ма	шу-а

Әнә Ләлә.
Әнә Әсма.
Әнә Алсу.

Ләлә, мә .
Әсма, мә .
Алсу, мә .

а — ә

Ул Муса.
Ул Алсу.

Әнә Ләлә.
Әнә Әсма.

Муса, мә . Ләлә, мә .

Алсу, мә . Әсма, мә .

ла	**на**	**ма**	**ша**	**са**
лә	**нә**	**мә**	**шә**	**сә**

И и

и-нә	ә-нә	нә-ни	и-сә	Ма-ил
и-лә	ә-ни	мә-ми	и-шә	На-ил

ис	иш	ал
ис-мә	иш-мә	ал-ма

Ләлә нәни.
— Әни, мәми.
— Мә, Ләлә, мәми.

а | у | ә | и

ә-ни	Ә-ни-сә	Сә-ли-мә
ма-ши-на	Ә-ми-нә	Ил-си-нә

Әнә Сә-ли-мә.
Сә-ли-мә ала.
Әнә На-ил.
Наил ма-ши-на ала.

ил	ис	иш
и-лә	и-сә	и-шә

ли | ни | ши | ми

Ч ч

ач	а-на	а-ша	шу-а
а-ча	ча-на	а-ча	шу-ам

са-на	ач	уч
ча-на	а́ч-ма	уч-ма

Наилә чана шуа.
Әнисә чана шуа.
Муса чана шуа.

а-ча	и-шә	мин
чә-чә	чи-шә	мич

Са-и-мә	ә-нә
На-и-лә	Ә-нәс

Сә-ли-мә
Сә-ли-сә

Әнә Әнәс.
Әнәс мич сала.

Әнә машина.
Машина чәчә.
Машина чәчә.

Р р

Са-ра Рә-ис

у-а	ал-ма	Са-ра	әр-чи
у-ра	ра-ма	са-ла	әр-ни

Рәис ала.
Сара рама ала.
— Мә, Рәис, рама.

у-ра	әр-чи	Са-ра
а-..	..-ни	..-ла

ур Нур	ул мул	шу шул	әр-чи әр-чим
шәл шәм	чәч мич	мин син	На-ил Ша-мил

Мин әрчим.
Шамил әрчи.
Әни аш сала.

Сы-лу	ы-лыс	чы-ра	чән-чи
су-лу	ы-лы-сы	чыр-шы	әр-ни

Чыршы.

Әнә чыршы. Чыршы ы-лыс-лы. Сылу ылыс ала. Ылыс чәнчи.

Сылу:
— У-у, әрни.

а-рыш	у-рыш	у-ра	Ил-сур
а-ры-шы	у-ры-ша	у-ра-лар	Ил-нур

Арыш.

Әнә арыш. Әнә машина.
Машина арыш ура.
Илсур, Илнур арыш уралар.

лы | ны | сы | шы | чы | ры

О о



о-ча	оч	он
а-ча	уч	ун

о-лы	со-ра	са-ры	о-чу-чы
со-лы	со-са	со-ры	о-чы-ра

Очучы.

Нур — очучы. Әнәс — очучы. Алар оча.
Сылу, Рәис:
— Ура! Ура!



шо-ма	со-са	о-чыр	мин
шу-ма	со-ра	о-чы-рам	син



Шар оча.

Мин шар о-чы-рам.
Син шар о-чыр.
Әнә шар оча.

Он или.

Әни он или.
Ул солы оны или.

а | у | ә | и | о | ы

Т т



ат	ә-ти	то-та	ир-тә
ут	ә-ни	то-ра	ил-тә

ач-ты	Ма-рат	а-ша-та
оч-ты	Са-мат	а-шат

Самат иртә тора. Марат та иртә тора. Марат солы сала. Самат су илтә. Алар ат ашата.

а .	. ун	ач . .	Ма . . .
у .	. ул	оч . .	Са . . .

ә-ти	тыр-ма	у-ты-ра	ил-тә
ә-ни	тор-на	у-тыр-та	ил-тәм

Нә-си-мә	Ә-ми-нә	На-и-лә
Рә-си-мә	Ә-ни-сә	Са-и-мә



Самат ала.
Әминә тырма ала.
Марат у-тыр-та.
Мин су ил-тәм.

та | ту | то | ты | тә | ти

З з

аз	у-за	су-за	та-за
уз	у-ра	ту-за	та-ра

На-за	тоз	зал	А-зат	у-зы-ша
Ро-за	тиз	зур	а-шат	ты-ры-ша

Наза уза.

Роза, Наза узыша.
— Наза, тиз, тиз!
Наза тырыша.
— Ура! Ура!
Наза уза.

та-ту	Ро-за	у-за	ча-на
та-шу	Ри-за	ту-за	са-на

ар-та	и-зә	ат	у-ты-ра
тар-та	си-зә	шат	ту-ты-ра

Алар тату.

Риза зур. Роза нәни.
Риза чана ала. Роза утыра.
Риза тарта. Роза шат.

уз	из	аз
у-за	и-зә	әз

К к

ук	аз	ул	кош	кыр
ак	каз	кул	кыш	кыз

ко-ра	ку-на	ка-кы	а-ша-та
то-ра	ку-ша	ка-ты	о-ша-та

Ук ата.

Рәшит ук ала. Ул ук ата. Ук туры оча.

Каз ашата.

Наза — зур кыз.
Наза каз ашата.
Ул солы сала.
Каз:
— Ка-ка-ка-ка!

ка-ла	Ка-зан	у-кы	кыш-ка	су-ык
ка-ра	ка-зык	ту-кы	тыш-ка	ку-ык

у-сак	ка-тык	у-ку-чы	са-рык
у-чак	ка-шык	ту-ку-чы	са-рык-лар

Укучы.

Сылу — укучы. Наза — укучы.
— Наза, укы!
Сылу, укы!
Алар тырыша.

Кыш.

Кыш суык. Кар оча. Роза сарыклар ашата. Кышка азык мул. Сарыклар тук.



мә	ки	кы-са	каз	кул
мәк	кис	ки-сә	кәз	кил

мәк	мич	чә-чәк	Кә-рим
ик-мәк	мич-кә	чә-кән	Кә-ри-мә

Мәк.

Әнә мәк. Мәк — матур чәчәк.
— Кәримә, мә чәчәк.

Икмәк.

Әни ка-мыр изә.
Ул мичкә икмәк сала.

ки-но ки-ло	Ка-мал Ка-мил	кар-та кир-тә	Ил-нур Ил-сур

чис-та чис-ло	ки-рәк си-рәк	ки-ло си-лос	ку-ку-руз ку-ку-ру-зы

Силос.

Әнә ку-ку-руз кыры. Машина кукуруз ура. Камил, Илсур силос сала.

Ә син?

Мин утын кисәм. Ә син?
Мин каз ашатам. Ә син?

ка | ку | кы | ки | кә



душ	и-дән	ал-да	Ди-лә
дус	и-мән	ан-да	Ди-нә

дис-тә	Да-мир	Ил-дар
чис-та	Ди-нар	Ил-дус

Душта.

Анда душ. Душта су. Дамир душта. Динар да душта. Душта тән чистара.

Дамир, Динар — дус-лар.

да	ду	ды	ди
та	ту	ты	ти

а-ру	а-ча	у-а	Ил-дар	да-ча
да-ру	ка-ча	ку-а	Ил-дус	ка-ча

кы-зык	та-ту	у-рам-да
ка-зык	та-шу	ур-ман-да

Дачада.

Әнә урман. Урманда дача. Дача матур. Динә дачада. Анда кызык.

Син кач.

— Илдус, син кач. Мин тотам. Илдус кача. Илдар кача. Дилә куа. Алар тату. Алар дус.

Га-та	Да-мир	да-га	ча-га
Га-зи	Га-мир	ду-га	чы-га

та-га	ту-ган	шо-ма-ра
ка-га	су-ган	шо-мар-та

Алар оста.

Гата такта кисә. Гамир такта шомарта. Гази кадак кага. Алар оста.

да . .	ча . .	су . . .
ду . .	чы . .	ту . . .

ал-га	чы-га	а-гар	Ил-гиз
ил-гә	чи-гә	ә-гәр	Ил-ги-зәр

а-га	у-рам-га	чи-тән-гә	да-га-га
а-гач	ур-ман-га	чи-рәм-гә	ду-га-га

Агач утырту.

Гата, Илгиз урамга чыга. Рәшит, Дилә урамга чыга. Алар агач утырта.

Урам чиста. Урам матур.

Ду-ду итә, дугага куна.
Чи-чи итә, читәнгә куна.



га | гә

Э э



эт	эш	эз-ли	әз
эз	эч	эш-ли	эз

әр-ни	ә-чи	эл-мә
эр-ли	э-чә	эл-мәк

Эз.

Урман. Кар тирән. Карда эз. Әнә эт. Эт эздән килә. Аучы да эздән килә.

Нинди эз икән ул?

кыр	сыз	тыш	тел	эт	эш
кер	сез	теш	тез	э-те	э-ше

эл	ис-те	те-ше	ки-те-рә
эл-геч	кис-те	те-ле	ки-ме-рә

Эштә.

Әни кер уа. Әти, энем су китерә. Мин кер эләм. Әти дә, әни дә эшли. Энем дә эшли. Мин дә эшлим.

кыр	с . з	т . ш
кер	с . з	т . ш

Б б

ал	а-ла	ба-ка	бе-лә	Са-бир
бал	ба-ла	ка-ба	би-рә	Са-бит

бо-лыт	Ба-ну	ак-ча	бу-лы-ша
Бу-лат	ба-ру	бак-ча	бе-ле-шә

Бал ала.

Сабир, Булат бал ала. Бану булыша. Булат Банугa бал бирә.

— Мә, Бану, бал.

Бану бал каба.

Бал татлы була.

а-лан	Ба-нат	бо-лан	быр-гы
ба-лан	Бу-лат	бу-ран	ба-ра-бан

ба-ра	бу-лыш	бу-кет	Кә-бир
бә-рә	бә-леш	би-лет	Бә-шир

Балан.

Урманда алан бар. Аланда балан бар. Без баланга бардык.

Әни балан бәлеше салды. Балан бәлеше бик тәмле булды.

Балык тоту.



Кәбир балык тота.
Бәшир дә балык тота.
Кәбир биш балык тот-ты.
Бәшир ун балык тот-ты.

у-ра	ур	кул	ту-за
ү-рә	үр	күл	тү-зә

ү-сә	үр-дәк	ү-лән	ба-лык
ү-тә	Үз-бәк	Гү-зәл	ба-шак

Үрдәкләр.

Бу күл зур. Ул бик тирән. Күл тирәсе чирәм. Күлдә камыш үсә.

Күлдә үр-дәк-ләр. Алар суга чума. Алар бака тота, балык тота.

у — ү

ау	бау	бо-зау	у-тау
әү	тау	бо-рау	у-рау

и-гәү	күл-мәк	Кәү-сәр
би-зәү	чүл-мәк	Рау-за

Күлмәк.

Рауза күлмәк тегә. Күлмәк матур була. Рауза аны Кәүсәргә бирә. Кәүсәр куана.

Гүзәл.

Гүзәл — укучы. Ул иртә тора. Чәчен үрә. Китабын ала. Дәрескә бара. Гүзәл — тырыш бала.

бу	су	бо-ру	и-гү
бау	сау	бо-рау	и-гәү

П п



туп	кап	а-на	ар-ба
тап	чап	а-па	ар-па

пар-та	па-лас	ки-тап	Чул-пан
кар-та	ла-пас	мәк-тәп	чур-тан

Туп.

Апа туп бирә. Талип туп ата. Чулпан тупны тота. Туп шап итә.

Китап.

Мәктәптә китап күп. Сабира апа китап бирә. Чулпан китап ала. Китап матур.

Китапны саклап тот!

Әдип песи чакыра:
— Пес-пес-пес!

Чулпан чеби чакыра:
— Чеп-чеп-чеп!

по-ши	по-са	шыр-пы	поч-мак
пе-си	пе-шә	кер-пе	пес-нәк

чып-чык	пы-чак	пе-ше-рә	поч-та
кап-чык	пыч-рак	тик-ше-рә	па-кет

Карга килә, казан аса.
Торна килә, тоз сала.
Песнәк килә, пешерә.
Чыпчык килә, тикшерә.
Әдип ашап бетерә.
Кап та коп!

Ө ө

он	ө-зә	оч	өз	өч
өн	ө-рә	өч	көз	көч
ө-не	тө-рә	уч	каз	кич

өс-тә	төл-ке	тө-бе	көн	ү-гез
өс-тәл	көл-ке	тө-се	төн	мө-гез

Өн.

Менә өн. Бу — төлке өне. Төлке өне агач тө-бен-дә. Төлке өндә тора.

Төлке.

Төн. Абзарда казлар. Төлке абзарга килә. Тышта эт өрә. Мөнир төлкене куа. Төлке урманга кача. Казлар исән кала.

көз	ө-тер	тө-шә	кө-рә	өл-ге	ө-леш
көз-ге	ө-тер-ге	тө-рә	кө-рәк	сөл-ге	кө-меш

бо-ра	то-ра	Гөл-нур
бө-рә	тө-рә	Гөл-сем

Кыш.

Алтын көз үтә. Көмеш кар төшә. Кыш була. Балалар мәктәпкә бара. Алар анда белем ала.

Дәрес беткәч.

Дәрес бетә. Балалар эшкә кала. Гөлсем гөлгә су сибә. Мөнир өстәл, парта сөртә. Гөлнур идән себерә. Бүлмә чиста була.

ө — о

Й й

ай	өй	уй	сай-ла	уй-на-гыз
тай	көй	куй	сай-ра	уй-ла-гыз

ту-гай	са-рай	Ай-дар	шар-дай
тур-гай	Сар-бай	Ай-рат	кан-дай

Тату булыгыз!

Айрат белән Айдарга әти ат алды.
— Минем ат,— диде Айдар.
— Ат минеке,— диде Айрат.
Айдар үзенә тарта. Айрат үзенә тарта.
— Ат и-ке-гез-не-ке дә. Тату булыгыз, бергә уйнагыз,— диде әни.

Та-быш-мак.

Үзе шардай,
эче кандай,
тәме балдай.

он	өз	о-зак	ө-зә	йө-гән
йон	йөз	йо-зак	йө-зә	йө-рәк

йом-гак	йом-ры	йо-мыр-ка	йорт	карт
йом-шак	йом-ран	йо-мыч-ка	корт	көрт

Йолдыз апа.

Йолдыз апа чеби үрчетә. Ул йомырканы ин-ку-ба-тор-га сала. Йомырка өч атнада тишелә.

Йолдыз апа че-би-ләр-не ашата. Балалар Йолдыз апага булыша.

Йомры йомшак сары йомгак
йөгереп йөри чирәмдә.

Кечкенә генә йорт —
эче тулы корт.

у-кы	ка-зы	ту-кы	ша-кы
у-кый	ка-зый	ту-кый	ша-кый

ә-би	ү-ти	а-ша	уй-на
а-бый	у-тый	а-шый	уй-ный

Уку залы.

Менә уку залы. Басыйр укый. Бакый рәсем карый. Айдар, Касыйм табышмак әйтә. Нәгыймә таба. Син дә тап әле.

Табышмак. Армый, талмый,
ат ар-тын-нан калмый.
(Арба.)

а	**у**	**о**	**ы**	**ый**
ә	**ү**	**ө**	**э-е**	**и**

Торналар.

Торна әйтә:
— Торыйк-торыйк,
дуслар булыйк,
өйләр корыйк.

Тыныч булыйк,
тату торыйк.
Торыйк-торыйк!
Торыйк-торыйк!

Каз бәбкәсе.

— Кыйгак! Кыйгак! —
дип кычкыра
болында каз бәбкәсе.
— Кыйгак, кыйгак!..
Кайда икән
әткәсе дә әнкәсе?

Я я

о-я	ко-я	кы-яр	я-за	ку-ян
ө-я	кө-я	ки-яр	я-та	кы-як

А-яз	ки-я	я-ма	я-шел	я-ра-та
Га-яз	ти-я	яр-ма	я-шен	я-са-та

Оя ясау.

Яз була. Сулар ага. Кошлар бәйрәме башлана. Аяз кош оясы ясый. Гаяз да кош оясы ясый. Алар кошларга оя куялар.

Өлгердем, өлгердем
ояны куярга.
Кунды ич бер кошчык
мин куйган ояга.

ал	аз	ат	ак	а-ра
ял	яз	ят	як	я-ра

а-га	а-як	ту-я	у-ян
я-га	та-як	ку-я	ку-ян

Якуп белән Гаяз.

Якуп куян ашата. Куян яшел үлән ярата. Гаяз куянга су бирә. Алар куян үстерә.

Куян.

— Куян, син кайда?
— Яшел тугайда.
— Куян, син кайда?
— Калын урманда.
— Куян, син кайда?
— Карлы буранда.

Ю ю



ю	юл	ю-а	ю-ка	кы-ю
а-ю	юк	ю-ан	ю-кә	ки-ю

у-ды	у-ка	у-ма	ул	ук
ю-ды	ю-ка	ю-ма	юл	юк

Аю.

Әнә аю. Аю күлгә килә. Ул баласын юа.
Аю әйтә:
— Менә, балам, су, битне, кулны ю, ю, ю!

. ка	. л	а .
. кә	. к	ба .

юр-га	ю-аш	юл-чы	ю-ын-ган	Ю-ныс
юр-ган	ю-ам	юл-да	ю-ыл-ган	Ка-юм

Юынам.



Мунчала, сабын кулда.
Тәнне юамын суда.
Юа-юа юылган:
сабын суда юк булган.

Күк юрга.

Күк юрга — күндәм ат. Юлда тиз йөри.
Күк юрга юаш. Юныс аны ярата.

ял	ян	як
юл	юн	юк

Е е

ел	е-лан	е-лый	ку-е	ка-ен
ел-га	е-рак	е-лак	ко-е	ка-еш

ел	тө-ен	ту-е	ко-е-на
еш	ти-ен	бу-е	ки-е-нә

Су буе.

Әнә елга. Елга бу-ен-да куе тал үсә. Елгада балалар су коена.

Ай су буе, су буе,
ярында таллар куе,
талларда кошлар туе,
кайтып булмый көн буе.

Табышмак. Утыра бер ак чүлмәк,
өстенә кигән йөз күлмәк.



Сабан туе.

Елга буе яшел үлән. Бүген анда Сабан туе. Әнә атлар чабыша. Менә егетләр көрәшә. Балалар туп уйный.

Әминә.

Әминә елый үкереп,
тубым суга төште дип.
— Чү, Әминә, елама:
туп батмый ул елгада.

я — ю — е

5 К 5/120

Җ җ

җир	җы-я	җи-лем	җи-тен	җәй
җил	җә-я	җи-лен	чи-тен	җөй

Эн-җе	кә-җә	у-җым	Мә-җит	төй-мә
эш-че	әр-җә	у-лым	Нә-җип	көй-мә

Яз.

Менә яз җитә. Көннәр җылына. Урамда кар сулары ага.

Нәҗип көймә ясый. Мәҗит җилкән куя. Көймә суда йөзә.

Җир астында җиз бүкән.

Җиз алачык эчендә җизни аты кешнидер.



Җиләк җыю.

Җәй. Көн җылы. Балалар урманда. Җәмилә белән Энҗе җиләк җыя.
Әнә Нәҗип килә. Монда җиләк күп.

җит-кәч | җы-лыт-кач | чы-гар-быз | җы-яр-быз

Җыр.

Матур җәй җиткәч,
көннәр җылыткач,
кырга чыгарбыз,
җиләк җыярбыз.



ат	ак	Ха-җи	ха-лат
хат	хак	Ху-җи	ха-лык

хә-бәр	хә-зер	Ә-хәт	рә-хәт
хә-тәр	хә-тер	Әх-мәт	рәх-мәт

Хат яза.

Хаҗи хәзер укый белә, яза белә. Ул хат яза.

Хәят апа!

Сездән хат килде. Рәхмәт. Бу хатны мин язам. Мин хәзер укый, яза беләм. Әнидән, әтидән сәлам.

Хаҗи.

Хә-ли-мә	бә-хет	хез-мәт	Ха-рис
Рә-хи-мә	бә-хет-ле	хөр-мәт	Ха-лит

Игенче.

Иң яхшы хезмәт — игенчелек.

Илдә бар кешене дә игенче ашата. Харис абый — игенче. Халит абый да игенче. Алар яхшы эшли.

Рәхмәт, балам.

Хәлимә әби карт. Ул ялгыз тора. Рәхимә — укучы. Ул Хәлимә әбигә су китерә.

— Рәхмәт, балам. Яхшы укы. Бәхетле бул,— ди Хәлимә әби.

В в

а-та	ак	а-ва	са-ва	та-вык
ва-та	вак	я-ва	са-выт	та-выш

ва-кыт	а-выл	Вә-си-мә	Ра-ви-я
ва-тык	а-выз	Вә-си-лә	Сә-ви-я

Вәсимә.

Вәсимә савытка ярма сала. Аны тавыкка сибә. Тавык:

— Кыт-кыт-кыт! — ди че-би-ләр-гә.

Чебиләр чаба. Вәсимә шатлана.

Авылда.

Вәли, Равия авылда яши. Авылда җәйге эш вакыты. Кешеләр кырда эшли. Вәли, Равия аларга булыша.

ва-за	за-вод	па-ро-воз
ва-гон	ди-ван	па-ро-ход

ста-кан	зве-но	сте-на
ста-нок	зво-нок	пла-кат

Заво́д.

Менә заво́д. Заводта́ эшчеләр эшли. Анда станокла́р күп. Заводта төрле машина эшләнә. Машиналар вагоннарга́ төялә. Алар авылларга җибәрелә.

Машина илебез кырларында ашлык чәчә, ура, суга, җилгәрә.

Ф ф



ил	уф	Са-фа	яф-рак
фил	У-фа	Ва-фа	туф-рак

хә-реф	Фә-ни-я	флаг	парк
дәф-тәр	Фи-ра-я	флот	зо-о-парк

Фил.

Вафа, Сафа зоопа́ркта.
Анда фил бар.
Фирая апа зоопаркта эшли.
Ул фил карый.
Фил — көчле хайван.
Ул җылы якта яши.
Фил — файдалы хайван.
Ул йөк ташый.

коф-та	фо-то	фаб-ри-ка
туф-ли	ло-то	фу-фай-ка

Нә-фи-сә	Ха-ли-дә	шарф
Нә-фи-га	Ха-ли-сә	торф

Фа́брика.

Нәфисә апа фабрикада эшли. Нәфига апа да фабрикада эшли. Нәфисә апа ко́фта бәйли. Нәфига апа фуфа́йка, шарф бәйли.

Алар яхшы эшлиләр. Безгә җылы киемнәр бәйлиләр.

Өс киеме: кофта, фуфайка, шарф.
Аяк киеме: гало́ш, ту́фли, боти́нка.

ун	а-на	я-на	тун	җил
уң	а-ңа	я-ңа	туң	җиң

аң	иң	у-ңа	күңел	ө-рәң-ге
таң	киң	ту-ңа	се-ңел	бә-рәң-ге



Яңгыр.

— Яңгыр, яңгыр, ни өчен
җирнең битен юасың?
Җирнең битен юа-юа
а-гарт-мак-чы буламсың?
— Явам, явам, гөл-чә-чәк-ләр
гөрләшеп үс-сен-нәр дип.
Алма, чия, сли-ва-лар
кызарып пеш-сен-нәр дип.

э-лен-гән	то-я-сың	ис-нә-гәч
өл-гер-гән	ку-я-сың	рә-хәт-лә-неп

Энҗе чәчәк.

Яшел яфрак эчендә
энҗе чуклар эленгән,
аңкып тора хуш исе,
ничек үсеп өлгергән.
Килеп керсәң урманга,
аның исен тоясың,
рәхәтләнеп иснәгәч,
иркен сулап куясың.

аңа	ми . .	у . .	күңел
я . .	си . .	шу . .	җи . . .
у . .	мо . .	ту . .	се . . .

Һ һ



а-ва	мич	Һа-ва	һәм	Ма-һи-рә
һа-ва	һич	Һа-ди	һәр	Ша-һи-дә

шә-һәр	Та-һир	һәр-кем	һа-ман
зә-һәр	За-һир	һәр-бер	Һа-рун

Шәһәр.

Шәһәр зур. Шәһәрдә завод, фабрика күп. Шәһәр урамында машина, кеше күп йөри. Эшчеләр эшкә бара.

Шәһәрдә мәктәпләр дә күп.

Таһир, Һади һәм Зәйтүнә мәктәпкә бара.

Ха-рис	Ва-хит	хуш	ах
Һа-ди	Ша-һит	һуш	аһ

яп	юн	яшь	ять-ле	и-юнь
ять	юнь	ямь	ямь-ле	и-юль

сә-гать	ши-гырь	кә-газь
Сә-гыйть	ша-гыйрь	кә-газь-дә

Дәрес әзерләү.

Өстәлдә сәгать. Сәгать кичке биш. Гайшә белән Сәгыйть дәрес әзерлиләр. Сәгыйть яза. Гайшә шигырь укый.

Кышкы шигырь.

Кар —
әйтерсең ап-ак кәгазь:
теләсәң шигырь,
теләсәң җыр яз.

дәрья	көнь-як	Мәрь-ям	ямь-ле
дөнь-я	төнь-як	Иль-яс	яшь-лек

Җәй җитте.

Менә җәй җитте. Без ял итәбез. Су керәбез, балык тотабыз. Олыларга булышабыз.

Безнең гаилә.

Безнең гаилә зур. Без авылда яшибез. Мәрьям апа фермада мал карый. Ильяс абый трактор йөртә. Әби өйдә тора. Без мәктәптә укыйбыз.

Безнең гаилә бик тату.

Кыш айлары: дека́брь, гыйнва́р, февра́ль.
Яз айлары: март, апре́ль, май.

Дәү әнием.

Тәмле ашлар пешерә,
Матур гөлләр үстерә,
Өебезнең нуры ул,
Барыбыздан олы ул.

Җылы оек, бияләй
Бәйли безгә көз җиткәч.
Мин дә аңа бүләкләр
Алырмын үсеп җиткәч.

Жж

га-раж	жур-нал
де-жур	жи-раф

Гараж.

Безнең авылда гараж бар. Гаражда машиналар күп. Минем абый машина йөртә. Ул иген, фураж ташый.

Безнең бакча.

Без бакчада яшелчә дә, җиләк-җимеш тә үстерәбез. Түтәлләрдә кишер, борыч, суган, баклажан үстерәбез. Бакча кырыйларында гөлҗимеш, крыжовник, карлыган куаклары үсә.

Ё ё

шо-фёр | са-мо-лёт
мон-тёр | вер-то-лёт

Шофёр машина йөртә.
Монтёр тимерчыбык суза.
Очучы самолётта оча.
Су буенда балалар учак яга.

6 К 5/120

Ц ц

цех	кон-верт	цирк	клуб
цех-та	кон-церт	цифр	клу-бы

стан-ци-я | це-мент | трак-тор

Конце́рт.

Авыл клубы зур. Без клубта концерт куйдык. Без анда биедек, җырладык.

Концерт күңелле булды. Әти, әниләр рәхмәт әйт-те.

Лю-ци-я апа.

Люция апа ти-по-гра-фи-я-дә эшли. Анда китап басыла. Люция апа җыю цехында эшли. Ул хәреф җыя.

Э э

Нәрсә баласы ни атлы?

экс-кур-си-я
экс-ка-ва-тор
э-кран
э-лектр

Атның колыны, тае бар.
Сыерның бозавы бар.
Сарыкның бәрәне бар.
Кәҗәнең бәтие бар...
Этнең баласы — көчек,
Ә куянныкы ничек?

Щ щ

щи	борщ	я-щик	щёт-ка
щи-ны	борщ-ны	я-щик-ны	щёт-ка-ны

э-лектр	ин-тер-нат	аш-ха-нә

Интернáт мәктәп.

Без интернат мәктәптә укыйбыз. Мәктәптә һәм ашханәдә дежур торабыз. Щётка белән идән себерәбез. Чүпне ящик-ка салабыз.

Ашханәдә безгә тәмле ашлар пешә. Без борщ, щи һәм ботка ашыйбыз.

Безнең интернат чиста һәм якты.

ак-кош	эс-се	үт-те	бо-лын-нар
кәк-күк	яс-сы	җит-те	һәм-мә-се

Аккошлар.

Матур яз үтте. Ямьле җәй җитте. Кәккүкләр тавышы тынды.

Көннәр эсселәнде. Күлләргә аккошлар килде. Болыннар, кырлар — һәммәсе аккошлар моңына күмелде.

Кошлар — безнең дусларыбыз.

Ъ

Сәгъ-дә	Нигъ-мәт
Сәгъ-ди	Җәгъ-фәр

Рә-фикъ	алъ-яп-кыч
Нә-фикъ	кулъ-яу-лык

Тауда.

Звонóк булды
физ-куль-ту-ра-га,
чаналар тартып,
без киттек тауга.
Таудан выжылдап
төшеп китәбез,
нәкъ апа торган
җиргә җитәбез.
Нигъмәт тә шуа,
Сәгъди дә шуа,
Нәфикъ аларның
артыннан куа...

Кар бабай.

Тәгәрәтеп ак карны,
ясадык кар бабайны.
Куйдык кишердән борын,
ясадык ике кулын.
Күзләре — кара күмер.
Дидек: «Син урам себер!»
Зур себерке тоттырдык,
көлешеп карап тордык.

Кошлар ашханәсе.

Кыш килдеме, кошлар өчен
без ашханә ачабыз
һәм кошларга эндәшәбез:
— Рәхим итеп, ашагыз!

Зәйнәп.

Зәйнәп, азап чигә-чигә,
абыйсына яулык чигә.
Ә яулыкның чит-читен
чигүе бигрәк читен.

Кем дәшә?

— Апа, нинди тавыш килә?
Әллә берәү эндәшә?
— Кем дә дәшми, көзге яңгыр
зо́нтик белән сөйләшә.

Кем нәрсә эшли?

Ат	чикләвек	ашый.
Тиен	печән	яра.
Малай	арба	чума.
Үрдәк	күлгә	ясый.

Менә шулай яз: Ат печән ашый.

Үскән кыз.

Әлфиянең бик тә үсәсе килә. Көн саен юына да, аяк очларына гына басып, көзгегә карый.

Бервакыт Әлфия кулъяулык юып маташа иде. Әнисе:

— Әтисе, күрче кызыбызны, үсеп килә бит! — диде.

«Әһә, менә ничек үсәләр икән!» — дип уйлады Әлфия.

Икенче юлы ул идән себерде, тәлинкә юды, өстәл җыйды. Курчагын да үзе киендерә башлады.

Әлфия ничек итеп зур үскән?

Һәркем эштә.

Безнең илдә һәркем эшли
үзе яраткан эштә:
фермаларда, заводларда
яки зур төзелештә.

Төлке белән Каз.

Бервакыт Төлке Казны тотып алган да:

— Каз, мин сине ашыйм! — дигән.

Каз боегып калган.

— Мин риза, Төлке. Тик син миңа бер биеп калырга рөхсәт ит,— дигән Каз.

— Әйдә, бие,— дигән Төлке.— Ашарга өлгерермен әле.

Каз, канатларын җилпеп, бер урында тыпырдый башлаган.

Төлке:

— Әй оста биисең, Каз! — дип көлә икән.

Ә Каз, канатларын җилпеп, бер урында торган-торган да очкан да киткән.

Төлке авызын ачып калган.

Басма.

Елга аркылы басма бар иде.

Бервакыт, шул басмадан чыкканда, Сара чак кына суга төшмәде. Басманың бер тактасы купкан икән.

Бу басма аша ике дус — Азат белән Илгиз дә чыкты. Алар да суга төшә яздылар.

Авылга кайткач, алар:

— Басмадан йөрмәгез, аның бер тактасы купкан,— диделәр.

Алар иптәшләренә әйтеп яхшы эшләделәр. Ә бит тагын да әйбәтрәк эшләргә була иде.

Әйтегез әле, ничек эшләсәләр яхшырак булыр иде?

Читен мәсьәлә.

Мәдинә мәсьәлә чишә. Ләкин мәсьәлә чыкмый.

— Китер, мин чишим! — ди абыйсы.

— Юк, үзем чишәм,— ди Мәдинә.

Ә мәсьәлә һаман чыкмый.

— Кая, үзем булышыйм! — ди әнисе.

— Юк, үзем чыгарам!

Мәдинә уйлады, исәпләде һәм мәсьәләне чиште.

Суык бабай.

Суык бабай, кил безгә
Яңа ел бәйрәменә,
Чыршы әйләнәсендә
Җыр җырлап әйләнергә.

Балтаң белән чыршыны
Кисеп аудар чанаңа.
Ул киенеп, ясанып,
Килсен безнең арага.

Чыршы бәйрәме.

Яшел чыршы,
Басып торчы
Өйнең түрендә!
Килдек бергә
Без биергә
Синең тирәңдә.
Җырлап-уйнап,
Узган чакта
Яныңнан дуслар,
Торсын шаулап
Һәр ботакта
Үткен ылыслар.

Батырларга,
Лачыннарга
Бергә җырлап дан,
Иптәшләрем —
Яшьтәшләрем
Узсын яныңнан.
Янсын, әйдә,
Шәмдәлләрдә
Бизәкле шәмнәр!
Уйнап-көлеп,
Шау-гөр килеп
Узсын бәйрәмнәр!

Иң матур сүз.

— Син яраткан иң матур сүз
нинди сүз, әйт, бәбкәем?
— Иң назлы сүз, иң якын сүз,
ул матур сүз — Әнкәем!

— Бар тагын бер иң матур сүз:
һәрвакыт син әйткәнең.
Анысы нәрсә?
— Ул матур сүз,
ул якын сүз — Әткәем!

— Үскәнем, я, инде син әйт!
— Иң матур сүз — Илкәем.
Анда син, мин — һәммәбез дә,
анда Әткәй-Әнкәем!

Шигырьне рольләргә бүлеп укыгыз.

Әлифба.

— Әлифба, Әлифба, беренче битеңне
ачкан көн хәтердә — зур бәйрәм шикелле.

Иң якын дустыбыз булдың син гел безнең,
һәр хәреф елмаеп әйтте үз исемен.

Һәм алар бик матур сүзләргә әйләнде,
сүз төзеп укуы кызыклы, күңелле!

Әлифба, Әлифба, китәсең бит инде,
җыр итеп җырлыйбыз иң соңгы битеңне.

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

Габдулла Тукай — татар халкының бөек шагыйре. Габдулла Тукай исемен һәркем белә. Ул зурлар өчен дә, кечкенәләр өчен дә бик күп шигырьләр язган. Балалар аның шигырьләрен бик яратып укыйлар.

Җир йокысы.

Кырга ак кардан
Юрган ябылган.
Җир язга чаклы
Йокыга талган.

Җир йоклый тыныч,
Күреп тәмле төш.
Уяныр әле,
Тукта, үтсен кыш.

Туган авыл.

Тау башына салынгандыр безнең авыл.
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул.
Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңа күрә сөям җаным-тәнем белән.

Гали белән кәҗә.

Безнең Гали бигрәк тату кәҗә белән.
Менә кәҗә карап тора тәрәзәдән.
Гали аны чирәм белән кунак итә,
Кәҗә рәхмәт укый: сакалын селкетә.

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ

Галимҗан Ибраһимов — танылган татар язучысы, галим һәм педагог. Ул укучылар өчен дәреслекләр дә яза. Мәктәп балалары аның «Яз башы», «Алмачуар» һәм башка хикәяләрен яратып укыйлар.

Алмачуар.

(Өзек.)

1

Мин кая басканымны белмим. Бер көндә әллә ничаклы үскән кебек булдым. Минем колыным бар. Ул айгыр! Төсе алмачуарга әйләнәчәк! Тирә-

якта дан торкан ике агасы кебек чабышкы булачак!

Әнә күрегез: ул ничек көмеш тавыш белән яңгыратып кешни! Ничек асыл сөякле гәүдәсе белән матурлап сикереп уйный!

Ул, әкияттәге баһадир кебек, ай үсәсен көн үсә, үзе көннән-көн матурлана бара.

2

Җәй, көз, кыш үтә. Яз килә.

Минем Алмачуар өченчегә керә. Бу яшькә җиткәч, тайларны «беренче сабан керде» дип сөйлиләр. Акрынлап, җиңелчәгә җигә башлыйлар.

Телләребез сөйләшмәсә дә, без бер-беребезне бик тирән аңлыйбыз. Өстен, ялын, койрыгын тазартканда, йөзеннән сыйпаганда, айгырым бертуктаусыз иһи... иһи... дип, йомшак кына кешнәп, иркәләнеп тора.

Бер дә шик юк, Алмачуар тиз арада Сабан туе буласын белә, анда үзенең чабасын да сизә һәм шуңа бик нык әзерләнә. Минем әзерләнүем дә аныкыннан ким түгел.

Әткәй белән Сафа бабай, шаярыпмы, чынлапмы, кайбер вакыт башка берәр малайны мендереп чаптыру турында сөйлиләр:

— Син яшьсең. Алмачуар да әле зур җирләрдә чабып өйрәнмәгән,— диләр.

Мин якын да килмим. Тагын әйтсәләр, күзләрем яшәрә башлый.

МУСА ҖӘЛИЛ

Муса Җәлил — герой шагыйрь, атаклы татар шагыйре. Ул үзенең кечкенә иптәшләре — кызлар белән малайлар өчен дә бик күп шигырьләр язган. Аның «Күке», «Беренче дәрес» кебек шигырьләрен укучылар яттан беләләр.

Беренче дәрес.

Без бу ел гына
Мәктәпкә килдек.
Аңарчы һаман
Бакчада идек.

Кулыбызда безнең
Яңа әлифба:
Менә монсы «а»,
Менә монсы «ба».

Без хәрефләрдән
Сүзләр ясыйбыз,
Шуннан соң җырлап
Укый башлыйбыз.

Бишек җыры.

Күз нурым син,
Матурым син,
Тулган аем!
Ай туганда
Йокла инде,
Матуркаем!
Такмак әйтер
Сиңа җилләр,
Алмагачы
Әкият сөйләр.
Йокла, нәни,
Йокла, бәби,
Әлли-бәлли,
Бәлли-бәү!

Әтәч.

Таң ата бугай,
Әтәч кычкыра:
— Кикрикүк,
Кикрикүк!

Я сузып кына,
Я бик еш кына:
— Кикрикүк,
Кикрикүк!

Без дә уяндык
Әтәч тавышына:
— Кикрикүк,
Кикрикүк!

Бакчага килдек
Ашыга-ашыга:
— Кикрикүк,
Кикрикүк!

А а	Аа	К к	Кк	Ф ф	Фф
Ә ә	Әә	Л л	Лл	Х х	Хх
Б б	Бб	М м	Мм	Һ һ	Һһ
В в	Вв	Н н	Нн	Ц ц	Цц
Г г	Гг	ң	ң	Ч ч	Чч
Д д	Дд	О о	Оо	Ш ш	Шш
Е е	Ее	Ө ө	Өө	Щ щ	Щщ
Ё ё	Ёё	П п	Пп	ъ	ъ
Ж ж	Жж	Р р	Рр	Ы ы	Ыы
Җ җ	Җҗ	С с	Сс	ь	ь
З з	Зз	Т т	Тт	Э э	Ээ
И и	Ии	У у	Уу	Ю ю	Юю
Й й	Йй	Ү ү	Үү	Я я	Яя

Учебное издание

Валитова Рамзия Гилязовна
Вагизов Салей Гататович

АЛИФБА

Учебник для 1 класса
четырёхлетней начальной татарской школы

Казань. Издательство «Магариф». 2005

Издание тридцать пятое

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Вәлитова Рәмзия Гыйләҗевна
Вагыйзов Сәләй Гататович

ӘЛИФБА

Дүртьеллык башлангыч татар мәктәбенең
1 нче сыйныфы өчен дәреслек

Утыз бишенче басма

Редакторы *Р. И. Раскулова*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы *Л. И. Матвеева*
Корректоры *Т. Н. Сәгъдуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 8.06.05. Форматы $70\times90^1/_{16}$.
Офсет кәгазе. «Букварная» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 7,61 + өст. б. 0,88 + форз. 0,29. Нәшер-хисап табагы 7,22 + өст. б. 0,81 + форз. 0,47.
Тиражы 5 000 д. Заказ К 5/120.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

ДУП «Полиграфия-нәшрият комбинаты».
420111. Казан, Бауман урамы, 19.


5
6
7
8
9
10
11
12
13
14
15
16
17
18
19
20


25
26
27
28
29
30
31
32
33
34
35
36
37
38
39
40

Д	э	Ү	ө	Ю	х	ң	ж
д	э	ү	ө	ю	х	ң	Ё
д	е	ү	Й	ю	В	Һ	ё
Г	е	П	й	Е	в	һ	Ц
г	е	п	й	Җ	в	һ	ц
г	Б	п	Я	җ	Ф	ь	Щ
г	б	п	я	җ	ф	Ж	щ
Э	б	Ө	я	Х	ф	ж	ъ

А	у	н	ш	ә	ч	ы	т
а	у	н	ш	ә	ч	ы	З
а	Л	С	М	И	Р	О	з
а	л	с	м	и	р	о	з
а	л	с	м	и	р	о	К
У	л	с	м	и	р	Т	к
у	Н	Ш	Ә	Ч	Ы	т	к
у	н	ш	ә	ч	ы	т	к

ка	ку	ко	кә	ки	ло	кы	ык	Кә
но	да	ду	ди	дә	га	Га	Да	Ди
ги	гә	эл	эч	эр	эз	ле	эш	ше
ме	че	те	ке	ри	ба	бә	би	Ба
бо	бу	тү	үр	Үз	па	Бү	пы	юм
по	пе	өс	мө	тө	кө	юр	яз	кый
Ай	ай	уй	йо	йө	ян	юл	яр	мый
ел	ен	еш	Ха	ха	хә	җә	җи	җы

ла	на	ал	ул	ун	су	Ал	ша	аш
ас	са	ам	ма	нә	лә	Лә	шу	Му
мә	ли	ни	ми	ис	сә	Әс	ши	иш
ил	ча	чу	ач	уч	чә	шә	На	Ма
чә	чи	Са	ра	әр	ур	Рә	сы	Ша
лу	лы	чы	ну	со	то	ры	шы	Сы
он	оч	та	ту	тә	ти	ты	шо	Ил
ат	ут	си	за	зә	Ро	Нә	Ри	Ка